ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СЕЛЕНГУШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

СӘЛӘНГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　КАРАР

«03» февраль 2020 ел　　　　　　　　　　　　№ 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль
районы Сәләнгеш авыл җирлегендә җирләү
буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге
нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр
кыйммәтен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2020 ел, 29 гыйнвар, 61 номерлы карары нигезендә Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 февраленнән Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче һәм 2нче кушымта нигезендә 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2019 елның 23 апрелендәге 14 нче карары 2020 елның 1 февраленнән үз көчен югалкан дип санарга.
3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге территориясендә мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам..

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Сәләнгеш авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе　　　　　　　　　А.Н. Пинин

Нурлат муниципаль районы
Сәләнгеш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 3 февралендәге 2 номерлы карарына 1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән ТР Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе.
*(православие йоласы буенча)*

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 2340,33 |
| 3. Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 944,51 |
| 4. Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 2840,02 |
| Барлыгы | 6124,86 |

Җитәкче А.Н. Пинин

Нурлат муниципаль районы
Сәләнгеш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 3 февралендәге 2 номерлы карарына 2 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән ТР Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе.
*(мөселман йоласы буенча)*

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Мәетне кәфенләү (төрү) | 1112,58 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле әйберләрне бирү һәм китерү | 1227,75 |
| 4. Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 944,51 |
| 5. Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 2840,02 |
| Барлыгы | 6124,86 |

Җитәкче А.Н. Пинин